СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39. E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　КАРАР

11.12.2023　　　　с. Верхний Услон　　　　№ 39-546

## Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең генераль планын раслау турында

Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегенең тотрыклы үсеше өчен шартлар тудыру максатларында, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Югары Ослан муниципаль районы Уставы нигезендә, җәмәгатьчелек фикер алышуларын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты килештергән генераль план проекты буенча нәтиҗәләрне исәпкә алып,

Югары Ослан муниципаль районы Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегенең генераль планын кушымталар нигезендә расларга.
2. Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советының 2012 елның 20 августындагы 23-103 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегенең генераль планы үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Югары Ослан муниципаль районы Советының икътисади үсеш, экология, табигый ресурслар һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы　　　　　　　　М.Г. Зиатдинов